Татарстан Республикасы
Кукмара муниципаль районының
Лубян авыл җирлеге Советы

Карар

23 ноябрь 2021ел №14

«Агачларны, куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны алуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 23 сентябрендәге 12 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының Лубян авыл Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

«Агачларны, куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны алуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Лубян авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 23 сентябрендәге 12 номерлы карары белән расланган агачларны, куакларны кисүгә, ябалдашларын кисүгә, утыртуга һәм күчереп утыртуга, газонны алуга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.3.1. пунктының 2 пунктчасында «агачларның, куакларның авария хәлендә булуы турында бәяләмә белән» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. 2.4.1. пунктының дүртенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3. 2.5.4. пунктын төшереп калдырырга;

1.4. 2.6.1. пунктының 4, 5, 7 пунктчасында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә Башкарма комитет яки муниципаль район җирле үзидарә органы» сүзләренә алмаштырырга»;

1.5. 2.6.1. пунктының 6, 11 пунктчаларында «Башкарма комитет» сүзен «төзелгән килешү нигезендә муниципаль районның җирле үзидарә органы яки Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга»;

1.6. 2.6.3. пунктында «Башкарма комитетның структур бүлекчәләре» сүзләрен «муниципаль районның җирле үзидарә органнары, Башкарма комитет» сүзләренә алмаштырырга;

1.7. 2.8.2 пунктның 2 пунктчасында яисә алу бик кирәк булган яшел утыртмаларны (авария хәлендәге агачлар) тикшерү нәтиҗәсендә гаризада күрсәтелгән яшел утыртмаларны алуның зарурлыгы расланмау» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.8. 2.8.2 пунктының 5 пунктчасында. (авария-торгызу эшләрен уздыруга яисә яшел утыртмаларны алып ату зарурилыгы булу белән (агачның, авария хәлендәге агачның төшү куркынычын юкка чыгару өчен) очраклардан тыш) сүзләрен төшереп калдырырга;

1.9. 2.8.4 пунктында «2 нче кушымтада» сүзләрен «3 нче кушымтада» сүзләренә алмаштырырга;

1.10. 3.4.2 пунктының дүртенче абзацында «, шулай ук авария-торгызу эшләрен уздыру өчен яисә яшел утыртмаларны алып ату зарурилыгы булганда (агачның, авария хәлендәге агачның төшү куркынычын юкка чыгару өчен)» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.11. 3.5.2.3 пунктын төшереп калдырырга;

1.12. 3.5.5 пунктында «; авария-торгызу эшләре башкарылганда яисә яшел утыртмаларны алып ату зарурилыгы булганда (агачның, авария хәлендәге агачның төшү куркынычын юкка чыгару өчен) гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтүдән файдалану өчен мөрәҗәгать иткән очракта – ике эш көне;» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.13. регламентның 2 нче кушымтасында «Авария хәлендәге агачлар кыска вакыт эчендә киселергә тиеш.» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны авыл җирлеге территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырып, халыкка игълан итәргә; шулай ук «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка җиткерелгәннән) соң үз көченә керә.

Җирлек башлыгы урынбасары      Р.Ф.Фахразиев